**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ**

# КАРАР

«07» 04 2021 ел Яр Чаллы № 43

ТР Тукай муниципаль районы Калмаш авыл җирлеге Калмаш авылы Западный микрорайонында Полевая, Луговая, Лесная, Төзүчеләр, Яшьләр, Якут Метшина, Муса Җәлил, Цветочная, Фатих Әмирхан, Җиңүнең 70 еллыгы, Лазурная урамнары буенча торак пунктны газлаштыру өчен территорияне планлаштыру проекты буенча халык тыңлауларын билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге Федераль законның 28 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советының 2018 елнын 28 декабрендәге вн/2 номерлы карары белән расланган Тукай муниципаль районында халык тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезнамәгә таянып,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. ТР Тукай муниципаль районы Калмаш авыл җирлеге Калмаш авылы Западный микрорайонында Полевая, Луговая, Лесная, Төзүчеләр, Яшьләр, Якут Метшина, Муса Җәлил, Цветочная, Фатих Әмирхан, Җиңүнең 70 еллыгы, Лазурная урамнары буенча торак пунктны газлаштыру өчен территорияне планлаштыру проекты буенча халык тыңлауларын үткәрергә.
2. Халык тыңлауларын бер көндә, 2021 елның 12 маенда 15.00 сәгатьтә үткәрергә, үткәрү урыны: ТР, Калмаш авыл җирлеге, Калмаш авылы, «Яшьлек» мәдәният йорты, Үзәк урамы, 32.
3. Халык тыңлауларын үткәрү өчен җаваплы итеп Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллинны билгеләргә.
4. Гражданнарның проект буенча фикер алышуда катнашу тәртибен кушымтадагыча расларга.
5. Халык тыңлауларын үткәрү турында мәгълүматны «Якты юл» («Светлый путь») газетасында бастырырга.
6. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
7. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам

Муниципаль район Башлыгы Ф.М. Камаев

Тукай муниципаль районы Башлыгының 2021 елның 07.04. 43 номерлы карарына кушымта

Гражданнарның фикер алышуда катнашу тәртибе

ТР Тукай муниципаль районы Калмаш авыл җирлеге Калмаш авылы Западный микрорайонында Полевая, Луговая, Лесная, Төзүчеләр, Яшьләр, Якут Метшина, Муса Җәлил, Цветочная, Фатих Әмирхан, Җиңүнең 70 еллыгы, Лазурная урамнары буенча торак пунктны газлаштыру өчен территорияне планлаштыру проекты буенча фикер алышуларда халыкның катнашуын тәэмин иту максатында эшләнгән һәм авыл җирлеге халкының проект буенча фикер алышуда катнашу, шулай ук халык фикерен исәпкә алу тәртибен җайга сала.

1. Гражданнарның проект буенча фикер алышуда катнашуы халык тыңлауларында катнашу һәм авыл җирлеге халкының проект буенча тәкъдимнәрен һәм искәрмәләрен язма рәвештә Тукай районы Башкарма комитетына җибәрү юлы белән гамәлгә ашырыла.
2. Проектның график һәм текст рәвешендәге материаллары Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты бинасында, мәгълүмати стендларда урнаштырылган.
3. Проект буенча материаллар белән танышу вакыты: дүшәмбе – җомга 9.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр (12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр төшке аш).
4. Проект Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырылырга тиеш.
5. Язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр 2021 елның 11 апреленнән 2021 елның 11 маена кадәр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: ТР, Яр Чаллы шәһәре, Муса Җәлил пр., 46 йорт, Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты бинасы, 203 кабинет.
6. Халык тыңлауларын үткәрү өчен җаваплы зат халык тыңлауларын әзерли һәм үткәрә, шулай ук гражданнарның проект буенча тәкъдимнәрен кабул итә һәм исәпкә ала.
7. Халык тыңлаулары секретаре проект буенча фикерләрне, тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне исәпкә алуны документлар белән тәэмин итә.
8. Халык тыңлаулары башланганчы, секретарь халык тыңлауларында катнашучыларны терки. Теркәү битендә халык тыңлауларында катнашучының фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган елы, яшәү урыны күрсәтелә.
9. Халык тыңлауларын уздырганда түбәндәге регламент билгеләнә:
   - чыгыш ясаучыга төп доклад өчен 20 минутка кадәр вакыт бирелә;
   - проект буенча фикер алышуга – 3 минутка кадәр;
   - фикерләрне кире кагу һәм искәрмәләр өчен – 2 минутка кадәр.
10. Халык тыңлауларын үткәрү барышында секретарь тарафыннан халык тыңлаулары беркетмәсе алып барыла. Беркетмәгә халык тыңлауларын оештыручы һәм секретарь имза куя.
11. Халык тыңлауларын оештыручы халык тыңлаулары уздырылган көннән

соң 2 көн эчендә халык тыңлаулары нәтиҗәләре буенча бәяләмә әзерли, анда мәҗбүри тәртиптә түбәндәгеләр күрсәтелә:

- халык тыңлауларына чыгарылган сорауның исеме;
- халык тыңлауларын үткәрү көне, вакыты һәм урыны;
- халык тыңлауларында катнашкан авыл җирлеге гражданнарының саны;
- халык тыңлаулары нәтиҗәләре буенча карар.

12. Бәяләмә халык тыңлауларын оештыручы тарафыннан имзалана һәм ул халык тыңлаулары беркетмәсе белән бергә мәҗбүри рәвештә «Якты юл» («Светлый путь») газетасында бастырылырга һәм районның рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.